РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**КАРАР**

7 август 2018 ел Буа ш. № 12-33

Вазифаи йөкләмәләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы буйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең хәбәр итү тәртибе турында

РФ Хезмәт кодексы, 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы «РФ җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законнар, ТР Буа муниципаль районы Уставы нигезендә Совет ТР Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1. Вазифаи йөкләмәләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы буйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең хәбәр итү тәртибен расларга (Кушымта).

2. ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарына:

2.1. ведомство буйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчеләрен әлеге карар белән таныштырырга;

2.2. җирле үзидарә органы ведомствосы буйсынуындагы оешма (учреждение) уставларына, шулай ук аларның җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт килешүләренә ведомство буйсынуындагы җитәкченең вазифаи йөкләмәләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында җирле үзидарә органы ведомствосы буйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесенә хәбәр итү йөкләмәсен билгеләүче үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге Карарны ТР Буа муниципаль районы Рәсми сайтындаһәм ТР хокукый мәгълүмат Рәсми порталының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлүен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башлыгы,
Буа муниципаль районы Советы рәисе М.А. Зяббаров

07.08.2018 елгы 12-33номерлы
Буа муниципаль районы Советы
карарына Кушымта

**Вазифаи йөкләмәләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерегә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы буйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең хәбәр итү тәртибе**

1.Әлеге Тәртип вазифаи йөкләмәләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерегә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы буйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең хәбәр итү процедурасын регламентлый

2. Әлеге Тәртиптә мәнфәгатьләр низагы дип вазифаны алмаштыручы, мәнфәгатьләр низагына юл куймау һәм көйләү чараларын күрергә тиешле йөкләмәсе булган вазифа алмаштыручы затның шәхси кызыксынучанлыгы (туры яки кыек) аның тарафыннан вазифаи (хезмәт) йөкләмәләрне (вәкаләтләрне үтәү) тиешенчә, объектив үтәүгә тәэсир итәрдәй сиуация аңлашыла.

3. ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы буйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесе коррупциягә каршы тору турында РФ законы һәм оешма (учреждение) уставы нигезендә мәнфәгатьләр низагы барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр низагына юл куймау һәм көйләү чараларын күрергә тиеш.

4. ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы буйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесе эш бирүчегә (наемга алучы вәкиленә) вазифаи йөкләмәләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерегә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында аңа мәгълүм булган көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

5. Вазифаи йөкләмәләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерегә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән вакытка ведомство буйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесеннән тормаган сәбәп белән хәбәр итү мөмкинлеге булмаса, сәбәпне ачыклаганнан соң, бер эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

6. Хәбәр язма формада вазифаи йөкләмәләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерегә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр рәвешендә языла (алга таба- хәбәр).

Хәбәрдә түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

а) хәбәрне тутыручы ведомство буйсынуындагы оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, аның вазифасы;

б) ведомство буйсынуындагы оешма җитәкчесенең шәхси кызыксынучанлыгы (туры яки кыек) аның тарафыннан вазифаи (хезмәт) йөкләмәләрне (вәкаләтләрне үтәү) тиешенчә, объектив үтәүгә тәэсир итәрдәй сиуацияненең тасвирламасы.

в) ведомство буйсынуындагы оешма җитәкчесе һәм (яки) аның белән якын туган яки үзлекләре булган затлар (ата-аналар, ир-хатын, балалар, абыйлар, апалар,

шулай ук ир-хатынның абыйлары, апалары, ата-аналары, ир-хатынның балалары һәм балаларның ир-хатыннары), гражданнар яки ведомство буйсынуындагы оешма җитәкчеләре һәм (яки) алар белән якын туган һәм үзлекләре булган затлар белән милек, корпоратив яки башка якын мөнәсәбәттә булган гражданнар тарафыннан вазифаи йөкләмәләрне (керемне акчалата, башка милек белән, шул исәптән милеккә булган хокуклар белән, милек характерындагы хезмәтләр белән, эшләнгән эш нәтиҗәләре белән алу мөмкинлеге) тиешенчә үтәүгә тәэсир итәрдәй шәхси кызыксынучанлыгының квалификацияләүче билгеләр;

г) шәхси кызыксынучанлык негатив тәэсир итүче яки негатив тәэсир итәргә мөмкин булган вазифаи йөкләмәләрнең тасвирламасы;

д) мәнфәгатьләр низагын барлыкка килү мөмкинлегенә юл куймау яки туган низагны көйләү чаралары;

е) хәбәр тутыру датасы;

ж) хәбәр тутыручының имзасы.

7. ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы **б**уйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесе эш бирүчегә 1 номерлы кушымтадагы форма буенча төзелгән хәбәр җибәрә.

8. Эш бирүче адресына килгән хәбәрләр алга таба карау өчен ТР Буа муниципаль районының эш урынында үз-үзеңне тотуга карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын көйләү Комиссиясенә бирелә (алга таба – Комиссия).

9. Хәбәрләрне теркәү Комиссия сәркатибе тарафыннан әлеге Тәртипнең 2 номерлы кушымтасында бирелгән тәкъдим ителәсе үрнәк буенча хәбәрләрне теркәү журналында башкарыла. Комиссия сәркатибе хәбәрдәге мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга тиеш. Конфиденциаль мәгълүматны таратуда гаепле зат РФ законы нигезендә дисциплинар, башка җаваплылыкка тартыла.

10. Теркәлү турындагы билгесе булган хәбәрнең копиясе ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы **б**уйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең кулына теркәлү журналына кул куйдырып бирелә яки алу турында хәбәр белән почта аша җибәрелә.

11. Хәбәрләрне алдан карау барышында Комиссия билгеләнгән тәртиптә хәбәр җибәргән затлардан анда бәян ителгән хәлләр турында аңлатма алырга һәм билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, РФ субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга җибәрергә хаклы.

12. Хәбәрләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча аларның һәрберсенә мотивацияле йомгак әзерләнә.

Хәбәрләрне алдан карау барышында алынган хәбәрләр, йомгаклар һәм башка материаллар Комиссия утырышына хәбәр кергән көннән алып җиде эш көне дәвамында бирелә.

Әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән запросларны җибәргән очракта, хәбәрләр, йомгаклар һәм башка материаллар эш бирүчегә хәбәр кергән көннән алып 45 көн дәвамында Комиссиягә бирелә. Күрсәтелгән вакыт озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә күпкә түгел.

13. Комиссия хәбәрләрне карый һәм ТР Буа муниципаль районы Советының _______ елгы ___ номерлы «_______» карары белән расланган Комиссия турында

Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә карар кабул итә, һәм кабул ителгән карарны эш бирүчегә җибәрә.

14. Эш бирүче Комиссия тарафыннан хәбәрләрне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) хәбәр җибәрүче зат вазифаи йөкләмәләрен үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагы юк дип танырга;

б) хәбәр җибәрүче зат вазифаи йөкләмәләрен үтәгәндә, шәхси кызыксынучанлык мәнфәгатьләр низагына китерә яки китерегә мөмкин дип танырга;

в) хәбәр җибәрүче зат тарафыннан мәнфәгатьләр низагына юл куймау һәм (яки) көйләү чаралары күрелмәгән дип танырга.

15.Әлеге Тәртипнең 14 пункт «б» пункт астында каралган карар кабул ителгән очракта, РФ законы нигезендә ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы **б**уйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесе мәнфәгатьләр низагына юл куймау һәм (яки) көйләү чараларын күрә яки чаралар күрүне тәэмин итә.

16. Әлеге Тәртипнең 14 пункт «б» пункт астында каралган карар кабул ителгән очракта, РФ законы нигезендә ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы **б**уйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесенә карата РФ Хезмәт кодексы, ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы **б**уйсынуындагы оешма (учреждение) уставы һәм хезмәт килешүендә каралган дисциплинар җәзага тартыла.

Хәбәрләр һәм хәбәрләрне крау белән бәйле башка материаллар ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы **б**уйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең шәхси делосына куела.

Вазифаи йөкләмәләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерегә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы буйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең хәбәр итү Тәртибенә 1 номерлы кушымта

*Тәкъдим ителә торган үрнәк*

________________________________

(вәкиллекле орган рәисенә, ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә) (кирәген сайларга)

__________________________________

(Ф.И.Ә.И.)

_____________________________(кемнән)

(Ф.И.Ә.И., вазифасы)

**Вазифаи йөкләмәләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында ХӘБӘР**

Вазифаи йөкләмәләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәген сайларга).

Шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүнең нигезе булып, түбәндәге хәлләр тора: ______________________________________________________________

Үтәүләренә шәхси кызыксынучанлык тәэсир итә яки тәэсир итәргә мөмкин вазифаи йөкләмәләр: ____________________________________________________
____________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр низагына юл куймау һәм (яки) көйләү буенча тәкъдим ителә торган чаралар: _________________________________________________________

Әлеге хәбәрне караганда, ТР ________ ______________ *(наименование района)* муниципаль районы Комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим) (кирәген сайларга).

«__» ________ 20__ ел.______________________________ _________________

(хәбәр җибәрүче затның имзасы) (имзаның расшифровкасы)

Вазифаи йөкләмәләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерегә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы буйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең хәбәр итү Тәртибенә 2 номерлы кушымта

**Вазифаи йөкләмәләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосы буйсынуындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан эш бирүченең хәбәрләрен теркәү журналы**

| т/б N | Хәбәр-нең теркәлү номеры | Хәбәр-не теркәү датасы | Хәбәр килгән | | Хәбәр теркәлгән | | | Хәбәрнең копиясен (копияне алдым, имза) алу яки аны почта аша җибәрү турында билге |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ф.И.Ә.И. | вазифа | Ф.И.Ә.И. | вазифа | имза | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |